**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«15» ноябрь 2019 ел** **№319**

2020 елга Азнакай муниципаль районы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле оешмаларның норматив чыгымнары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уставы белән, **карар бирәм:**

1. 2020 елга расларга:

- 1 нче кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

- балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2. «Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны.

- әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнар гамәлдә булган чор дәвамында яңадан карау дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буена бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://aznakayevo.tatar.ru.веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары Г. Г. Сөләймановага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
«_____»____________2019 № ______

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

**Туристлык-туган якны өйрәнү, экология-иология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле**

**мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Юнәлеш Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Беренче уку елында 1 укучыга бер елга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5569 | 10314 | 12376 |
| | авыл җирлеге | 5970 | 11055 | 13266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5468 | 10126 | 12151 |
| | авыл җирлеге | 5868 | 10867 | 13041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5873 | 10876 | 13051 |
| | авыл җирлеге | 6273 | 11617 | 13940 |
| Туризм һәм туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5671 | 10501 | 12601 |
| | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 5671 | 10501 | 12601 |
| | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5671 | 10501 | 12601 |
| | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5266 | 9751 | 11702 |
| | авыл җирлеге | 5666 | 10493 | 12591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5266 | 9751 | 11702 |
| | авыл җирлеге | 5666 | 10493 | 12591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5671 | 10501 | 12601 |
| | авыл җирлеге | 6071 | 11242 | 13491 |